| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>РЫБНО-СЛОБОДСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАЛЫК БИСТӘСЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

21.02.2019 пгт. Рыбная Слобода № 67пи

Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты опека һәм попечительлек бүлеге карамагында булганнарның милке белән алыш-биреш ясау өчен рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 27.07.2010 ел, №210-ФЗ Федераль закон, Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең «Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан яңа редакциядә күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр исемлеген раслау турында» 19.11.2013 ел, № 231пи, «Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында» 2016 елның 21 июнендәге 96пи номерлы карарларына ярашлы рәвештә КАРАР БИРӘМ:

1. Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты опека һәм попечительлек бүлеге карамагында булганнарның милке белән алыш-биреш ясау өчен рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын расларга (кушымта).
2. Үз көчен югалткан дип танырга:
Балык Бистәсе Башкарма комитеты тарафыннан 2014 елның 21 июлендәге 133пи номерлы карары белән расланган «Балигъ булмаган бала мәнфәгатьләрендә торак хосусыйлаштыру өчен, Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты опека һәм попечительлек бүлеге тарафыннан опекунга, торакны хосусыйлаштыру өчен рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты»;
Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында»гы 2016 елның 1 июлендәге 107пи номерлы карарының 25 пункты.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнашкан рәсми сайтында һәм Интернет

мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек бүлегенә йөкләргә.

Җитәкче Р.Л. Исланов

Балык Бистәсе муниципаль
районы Башкарма комитетының
21.02.2019 ел, № 67пи карары
белән расланды

**ОПЕКА ҺӘМ ПОПЕЧИТЕЛЬЛЕК БҮЛЕГЕ КАРАМАГЫНДА БУЛГАННАРНЫҢ МИЛКЕ БЕЛӘН АЛЫШ-БИРЕШ ЯСАУ ӨЧЕН РӨХСӘТ БИРҮ БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ ХЕЗМӘТЕ КҮРСӘТҮНЕҢ АДМИНИСТРАТИВ РЕГЛАМЕНТЫ**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Регламент Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты опека һәм попечительлек бүлеге карамагында булганнарның милке белән алыш-биреш ясау өчен рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын билгели (алга таба – хезмәт күрсәтү).

1.2. Дәүләт хезмәтен алучылар: физик затлар (опекуннар)

1.3. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә. Дәүләт хезмәтен башкаручы – Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек бүлеге (алга таба – опека һәм попечительлек органы).

1.3.1. Башкарма комитетның урнашу урыны: 422650, ш.т.п. Балык Бистәсе, Ленин урамы, 48 йорт.

кабул итү графигы: көн саен, шимбә һәм якшәмбе - ял.
Дүшәмбе - җомга 8.00 сәгатьтән 16.30 сәгатькә кадәр.
Төшке аш 12.00 сәгатьтән 13.30 сәгатькә кадәр.

Керү пропуск һәм (яки) шәхесне раслаучы документ буенча башкарыла.

1.3.2. Башкарма комитетның кабул итү бүлмәсе телефоны: (8-84361)22-113.

1.3.3. Рәсми сайт адресы: http://www.ribnaya-sloboda.tatarstan.ru, электрон почта адресы: balyk-bistage@tatar.ru.

1.3.4. Дәүләт хезмәте турында мәгълүмат түбәндәге юллар белән алынырга мөмкин:

дәүләт хезмәте күрсәтүче опекуннар (яки попечительләр) белән эшләү бинасында урнашкан дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган мәгълүмат стендлары аша;

Башкарма комитетка телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яки телефон буенча);

Башкарма комитетка язма (шул исәптән электрон документ формасында) мөрәҗәгать иткәндә;

1.4. Хезмәт күрсәтү түбәндәге норматив актлар нигезендә гамәлгә ашырыла:

- Россия Федерациясе Конституциясе (12.12.1993) (алга таба - РФ Конституциясе) (РФ законнары җыелмасы, 26.01.2009, № 4, 445 ст.);

- Россия Федерациясе Граждан кодексы (беренче өлеш) (алга таба-РФ ГК) («Россия Федерациясе законнары җыелмасы”, 05.12.1994, № 32, 3301 ст.)

- Россия Федерациясенең 2004 елның 29 декабрендәге 188-ФЗ номерлы Торак кодексы (алга таба – РФ ТК) («Россия Федерациясе законнары җыелмасы», 03.01.2005, № 1 (1 өлеш), 14 ст.);

- «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 27.07.2010 № 210-ФЗ Федераль закон (алга таба-210-ФЗ номерлы Федераль закон) (РФ законнары җыелмасы, 02.08.2010, № 31, 4179 ст.);

- «Психиатрия ярдәме һәм аны күрсәткәндә гражданнар хокуклары гарантияләре турында» 1992 елның 2 июлендәге 3185-I номерлы Россия Федерациясе Законы (алга таба – 3185-I номерлы РФ Законы) («Халык депутатлары Советы һәм Россия Федерациясе Югары Советы ведомостьлары», 20.08.1992, № 33, 1913 ст.)

-- «Күчемсез милеккә хокукларны һәм аның белән алыш-бирешләрне дәүләт теркәвенә алу турында» 1997 елның 21 июлендәге 122 – ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба-дәүләт теркәве турында ФЗ) («Россия Федерациясе законнары җыелмасы»,28.07.1997, № 30, ст. 3594);

- «Персональ мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба-152-ФЗ номерлы Федераль закон) (»Россия Федерациясе законнары җыелмасы», 2006, № 31 (1ч), 3451 ст.);

- «Опека һәм попечительлек турында» 2008 елның 24 апрелендәге 48-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба-48-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 28.04.2008, № 17, 1755 ст.);

- «Татарстан Республикасында опека һәм попечительлек органнары эшчәнлеген оештыру турында» 2004 елның 27 февралендәге 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы (алга таба – 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы) (Татарстан Республикасы, № 43-44, 02.03.2004);

- «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына опека һәм попечительлек өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2008 елның 20 мартындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы (алга таба – 7-ТРЗ номерлы ТР Законы) (Татарстан Республикасы, № 60-61, 25.03.2008);

- Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880нче номерлы карары (алга таба – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 880-нче карары) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнарының норматив актлары җыентыгы, 08.12.2010, № 46, 2144 ст.);

- Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы (алга таба - Устав);

- Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты турында нигезләмә (алга таба-БК турында Нигезләмә);

- Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек бүлеге турында нигезләмә (алга таба-бүлек турында Нигезләмә);

- Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре (алга таба-Кагыйдәләр).

1.5. Әлеге Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

- опека – суд тарафыннан эшкә яраксыз дип таныган гражданнарны урнаштыру формасы, опека һәм попечительлек органы тарафыннан билгеләнгән гражданнар (опекуннар) опекага алынган затларның законлы вәкилләре булалар һәм алар исеменнән һәм аларның мәнфәгатьләрендә юридик яктан әһәмиятле барлык гамәлләр башкаралар;

-опекага алынган зат – аңа карата опека яки попечительлек билгеләнгән гражданин.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына таләпләр атамасы | Стандартка таләпләр эчтәлеге | Дәүләт хезмәтен яки таләпне билгеләүче норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1 Дәүләт хезмәте күрсәтү исеме | Опекунга карамакта булган зат мәнфәгатьләрендә торак белән алыш-бирешне хосусыйлаштыруга рөхсәт бирү | РФ ГК;<br>48-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>8-ТРЗ номерлы ТР законы |
| 2.2. Хезмәт күрсәтүче орган исеме | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты<br>Дәүләт хезмәтен башкаручы –опека һәм попечительлек бүлеге | Устав,<br>7-ТРЗ номерлы ТР законы |
| 2.3. Хезмәт нәтиҗәсен тасвирлау | Опекунга карамакта булган зат мәнфәгатьләрендә торакны хосусыйлаштыруга рөхсәт итү турында, яки рөхсәт бирмәү турында боерык. | РФ ГК;<br>48-ФЗ номерлы Федераль закон ;<br>8-ТРЗ номерлы ТР законы |
| 2.4. Хезмәт күрсәтү вакыты | Мөрәҗәгать итүчедән барлык кирәкле документлар кабул ителгәннән соң 15 көн эчендә.<br>Карар әзерләү башка оешмаларга сораулар җибәрүне, яисә өстәмә консультация бирүне таләп иткән очракта, Башкарма комитет җитәкчесе карары буенча мөрәҗәгатьне карау вакыты 30 эш көненә кадәр озайтылырга мөмкин. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турындагы карар 15 көн эчендә кабул ителә. Тиешле карар гариза бирүчегә почта аша җибәрелә, я кабул итү вакытында бирелә | |
| 2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен закон яки башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге | 1. опекун яки попечительнең карамактагы затның милке белән алыш - биреш итүгә рөхсәт турында гаризасы (мәҗбүри шарт-карамактагы затның мөлкәти хокукларын саклау һәм карамактагы затның мәнфәгатьләрендә килешү кылу). Балигъ булмаган баланың мөлкәте кимегән очракта әлеге алыш-бирешкә китергән авыр сәбәпләрне (документаль рәвештә расланган) күрсәтергә<br>2. опекага алынган зат урнаштырылган учреждение администрациясе карамактагы затның мөлкәте белән алыш-биреш ясауга рөхсәт турында гариза (сәбәпләрен күрсәтергә);<br>3. тәрбияләнүченең әлеге учреждениедә булуы турында белешмә;<br>4. опекун яки попечитель билгеләү һәм опекун яки попечитель билгеләү турында хокукый акт (карар, боерык, карар һ. б.); | РФ ГК;<br>48-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>8-ТРЗ номерлы ТР законы |

| | | |
|---|---|---|
| | 5. гражданны хокуктан файдалануга сәләтсез яки мөмкинлекләре чикле дип тану турында законлы көченә кергән суд органы карарының күчермәсе;<br>6. тапшырыла торган мөлкәтне милекчеләрнең (әгәр андыйлар булса) уртак мөлкәтне читләштерүгә ризалык турында гаризасы (язма рәвештә);<br>7. сату-алу килешүе төзүгә (алмашу, бүләк итү һ. б.) ризалык турында опекага алынган зат исеменә милеккә хокук сатып алучыларның язма рәвешендә гариза);<br>8. карамактагы затның мөлкәтен башка торак сатып алмыйча читләштергән очракта (стационар социаль тәэминатта опекага алынган психоневрологик типтагы интернатта опекага алынган очракта) саклык кенәгәсе (опекага алынган, килешүне гамәлгә ашырганнан соң алынган акча кая кертелә);<br>9. карамактагы затның сәламәтлеге торышы һәм аның мөстәкыйль яшәү мөмкинлеге булмау турында медицина бәяләмәсе;<br>10. карамакта булган затның читләштерелүче милкенең, шулай ук карамакта булган зат исеменә сатып алынган мөлкәтне бәяләү бәясе | |
| 2.6. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган һәм мөрәҗәгать итүче аларны тапшырырга хокуклы норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге | - Бердәм дәүләт хокук реестрыннан (Татарстан Республикасы буенча дәүләт теркәве, кадастр һәм картография Федераль хезмәте идарәсе) алынган опекага алынган затның (эшкә яраксыз затның) милке турында мәгълүмат;<br>- Торак-коммуналь хуҗалык идарәсеннән яки ТСЖДАН йорт кенәгәсеннән күчермә.<br>- Торак биналарның санитар һәм техник кагыйдәләр һәм нормаларга туры килүе турында ЖКХ яки ТСЖдан белешмә. | |
| 2.7. Норматив хокукый актларда каралган очракларда хезмәт күрсәтү өчен таләп ителә торган һәм хезмәт күрсәтүче башкарма хакимият органы тарафыннан гамәлгә ашырыла торган дәүләт хакимияте органнары һәм аларның структур бүлекчәләре исемлеге | Килештерү таләп ителми | |
| 2.8. Хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләнүләрнең тулы исемлеге | 1. Тапшырылган документларның 2.5 пунктта күрсәтелгән исемлегенә туры килмәве.<br>2. Тапшырыла торган документлардагы алдан билгеләнмәгән төзәтмәләр | |
| 2.9. Хезмәт күрсәтүне туктатып тору яисә баш | Дәүләт хезмәтләрен күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләнүләр каралмаган. | РФ ГК;<br>48-ФЗ номерлы |

| | | |
|---|---|---|
| тарту өчен нигезләнүләрнең тулы исемлеге | Билгеләнгән мәгълүмат хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тора:<br>- дәүләт хезмәте күрсәтү өчен нигез юк;<br>- административ регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан бирелмәгән;<br>- опекага алынган затның граждан һәм милек хокукларын кысу;<br>- гариза бирүче биргән документларда дөрес булмаган яки ялган мәгълүматлар булуы ачыкланганда. | Федераль закон;<br>8-ТРЗ номерлы ТР законы |
| 2.10. Хезмәт күрсәтүләр өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Дәүләт хезмәте түләүсез күрсәтелә | |
| 2.11. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәт күрсәтүләр өчен шул исәптән мондый түләүне исәпләү методикасы турында мәгълүматны да кертеп түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган дәүләт хезмәтләрен күрсәтү өчен түләү юк | |
| 2.12. Хезмәт күрсәтү турында сорату биргәндә һәм хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты | Хезмәт алучыларның аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтү вакыты 15 минуттан артмаска тиеш. | |
| 2.13. Хезмәт күрсәтү турында, шул исәптән электрон формада гариза бирүченең гаризасын теркәү срогы | 1 көн дәвамында | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, мөрәҗәгать итүчеләрне көтү һәм кабул итү урынына, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турында Россия Федерациясе законнары нигезендә әлеге объектларның инвалидлар өчен мөмкин булган урынга карата, мондый хезмәтләр күрсәтү тәртибе турында визуаль, текст һәм | Дәүләт хезмәтен күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы белән җиһазландырылган биналарда һәм документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһазлар, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда башкарыла.<br>Инвалидларның дәүләт хезмәте күрсәтү урынына тоткарлыксыз керү мөмкинлеге тәэмин ителә (бинага уңайлы керү- чыгу һәм аның чикләрендә хәрәкәт итү).<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында визуаль, текст һәм мультимедиа мәгълүматы гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла | |

| | | |
|---|---|---|
| мультимедиа мәгълүматын урнаштыру һәм рәсмиләштерү турында таләпләр | | |
| 2.15. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең һәркем өчен мөмкин булуы һәм сыйфаты күрсәткечләре, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең вазыйфаи затлар белән багланышлары, муниципаль хезмәт күрсәткәндә дәвамлылыгы һәм аларның мөмкинлеге, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә муниципаль хезмәт алу мөмкинлеге, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгеннән читтә урнашкан эш урыннарында, шул исәптән мәгълүмати-коммуникацион технологияләр кулланып, муниципаль хезмәт күрсәтүнең барышы турында мәгълүмат алу мөмкинлеге | Муниципаль хезмәт күрсәтүнең һәркем өчен мөмкин булуы күрсәткечләре булып тора:<br>җәмәгать транспортының һәркем файдалана алырлык зонасында урнашкан бина Ленин урамы 48 йорт;<br>кирәкле сандагы белгечләр, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул итеүә торган биналар булу;<br>мәгълүмати стендларда, «Интернет» челтәрендәге мәгълүмат ресурсларында http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru сайтында, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталында муниципаль хезмәт күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булу;<br>башка затлар белән беррәттән, инвалидларга хезмәт күрсәтүгә комачаулаучы киртәләрне җиңеп чыгарга ярдәм күрсәтү.<br>муниципаль хезмәт турында консультация алу, муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза бирү, КФҮ аша муниципаль хезмәт күрсәтүләрдән нәтиҗә алу мөмкинлеге;<br>мәгълүмат стендларында муниципаль хезмәт күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат, муниципаль районның рәсми сайтында http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru Интернет челтәрендә, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталында<br>Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталындагы шәхси кабинет аша гариза бирү, муниципаль хезмәт күрсәтүнең барышы турында мәгълүмат алу, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен электрон рәвештә алу мөмкинлеге.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтүнең сыйфаты булмау түбәндәгеләр белән характерлана:<br>мөрәҗәгать итүчеләргә документлар кабул итү һәм бирү чиратлары;<br>муниципаль хезмәт күрсәтү вакыты кысаларын бозу;<br>муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата шикаять;<br>муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең гариза бирүчеләргә карата әдәпсез, игътибарсыз мөнәсәбәтенә карата шикаятьләр.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү турында мөрәҗәгать иткәндә һәм дәүләт хезмәте нәтиҗәсе алган очракта муниципаль хезмәт күрсәтүче | |

| | | |
|---|---|---|
| | вазыйфаи затның һәм мөрәҗәгать итүченең бер тапкыр үзара хезмәттәшлеге күздә тотыла. Хезмәттәшлекнең озынлыгы регламент белән билгеләнә.<br>Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә (алга таба – КФҮ) дәүләт хезмәте күрсәткәндә, КФҮнең ерак урнашкан эш урыннарында консультация бирүне, документлар кабул итүне һәм бирүне КФҮ белгече башкара.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтүнең барышы турында мәгълүмат гариза бирүче тарафыннан алынырга мөмкин:.http://www.uslugi.tatarstan.ru һәм http://www.gosuslugi.ru дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталында, КФҮдә | |
| 2.16. Электрон формада хезмәт күрсәтү үзенчәлекләре | Хезмәт күрсәтү тәртибе турында консультацияне Башкарма комитетның Интернет-кабул итү бүлмәсе аша алырга мөмкин.<br>Электрон формада хезмәт күрсәтелми | |

## 3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм үтәү сроклары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә гамәлләр эзлеклелеген тасвирлау

3.1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге административ процедураларны үз эченә ала:

- опекага алынган зат мәнфәгатьләрендә торак белән алыш-биреш ясауны хосусыйлаштыруга рөхсәт бирү мәсьәләләре буенча опекуннарга мәгълүмат бирү һәм консультация бирү;
- гаризалар һәм документлар кабул итү, аларны теркәү;
- бирелгән документларны әлеге Административ регламент таләпләренә туры килү-килмәүгә тикшерү үткәрү;
- Бердәм дәүләт хокук реестрыннан (дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе) опекадагы баланың (эшкә яраксыз затның) милке турында мәгълүмат соратып алу;
- дәүләт хезмәтләрен күрсәтү яисә күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул итү.

3.2. Опекунның яшәү урыны буенча муниципаль берәмлек Башкарма комитетының опека һәм попечительлек бүлегенә консультация сорап мөрәҗәгать итүе административ процедураны башлау өчен нигез булып тора. Опекун белгечкә паспорт бирә, ә Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда аның шәхесен таныклаучы башка документ; опекун билгеләү һәм билгеләү турында норматив хокукый акт (карар, күрсәтмә, боерык һ.б.) яки опекун таныклыгы.

Тиешле бүлек белгече, мәгълүмат бирү һәм консультация бирү процедуралары кысаларында гражданнарга консультация бирү һәм мәгълүмат бирү өчен җаваплы:

- дәүләт хезмәте күрсәтү шартларын һәм тәртибен җайга сала торган норматив хокукый актлар турында мәгълүмат бирә;

- опекунны эшкә яраксыз балигъ булган зат мәнфәгатьләрендә торакны хосусыйлаштыруга рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе белән таныштыра;

- опекунны опекага алынган зат катнашыннан башка, торакны хосусыйлаштыруга рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе белән таныштыра;

- опекунга торакны хосусыйлаштыруга рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча аңа дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту сәбәпләре турында аңлата;

- торак урыннарны хосусыйлаштыруга рөхсәт бирү өчен кирәкле документлар исемлеген тәкъдим итә;

- элек опекага алынган торак хосусыйлаштыру хокукыннан файдаланган очракта, торак урыннарны хосусыйлаштыруга рөхсәт бирү өчен кирәкле документлар исемлеген бирә;

- дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гариза язу формасы турында аңлата.

Консультация телдән мөрәҗәгать иткән көндә үткәрелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтүне башлап җибәрү өчен документларны рәсмиләштерү өлешендә гариза бирүчегз ярдәм күрсәтүне таләп итми.

Процедураларның нәтиҗәсе: составы, күрсәтелә торган документлар формасы һәм хезмәт күрсәтүне алуның башка мәсьәләләре буенча консультацияләр.

Консультация һәм мәгълүмат бирү буенча административ процедураларны үтәүнең гомуми вакыты -30 минутка кадәр.

Гражданнарга консультация һәм мәгълүмат бирүне гамәлгә ашыручы белгеч, конфиденциаль мәгълүматларны исәпкә алып, консультацияләрнең тулылыгы, грамоталылыгы һәм һәркем файдалана алырлык булуы өчен шәхси җаваплылык тота.

3.3. Документларны кабул итү буенча административ процедураны башлап җибәрү өчен гариза һәм әлеге Административ регламентның 2.5 пунктында каралган документларны тапшыру нигез булып тора.

Гаризалар һәм документларны кабул итү өчен җаваплы белгеч әлеге Административ регламентның 2.5 пунктында каралган кирәкле документларның комплектлылыгын һәм булуын тикшерә, шул исәптән:

- Граждан шәхесен билгели - шәхесне раслаучы документ, шулай ук опека билгеләү турындагы норматив-хокукый актны тикшерә;

- опекун биргән барлык кирәкле документларның булу-булмавын һәм билгеләнгән таләпләргә туры килүен тикшерә;

- документларны тутыруның дөреслеген тикшерә;

- документ текстлары аңлаешлы язылган, карандаш белән тутырылмаган булуын билгели;

- бу документларда дөрес булмаган язулар, килештермичә язылган сүзләр һәм башка килешмәгән төзәтүләр булмавын, булган очракта аларның эчтәлекне һичшиксез аңлатырга комачауламавын, шулай ук документларга җитди зыян китерелмәвен билгели;

- кергән документларны терки;

- опекунга торакны хосусыйлаштыруга рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча дәүләт хезмәте күрсәтү өчен документлар пакетын формалаштыра.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән документлар.

Гамәлләр башкаруның максималь вакыты-10 минут.

3.3.1. Бүлек белгече тиешле органнарга түбәндәге сораулар юллый: опекага алынган затның (эшкә сәләтсез затның) Татарстан Республикасы буенча бердәм

дәүләт хокук реестрыннан (дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәте Идарәсеннән); йорт (фатир саен) кенәгәсеннән (ТКХ ИК яисә ТМШ) күчермә бирү турында.

Процедураларның нәтиҗәсе: җибәрелгән сораулар: бердәм дәүләт реестрыннан опекага алынган затның (эшкә сәләтсез затның) милке турында белешмә, яшәү урыныннан йорт (фатир) кенәгәсеннән күчермә.

Максималь гамәлдә булу срогы 3 эш көне тәшкил итә.

3.3.2. Ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша кергән сораулар нигезендә мәгълүматлар белән тәэмин итүче белгече соратып алына торган документларны (мәгълүматларны) тапшыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар, әгәр ведомствоара таләпкә җавап әзерләүнең һәм ведомствоара таләпкә җибәрүнең федераль законнар, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең хокукый актлары һәм федераль законнар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясе субъектларының норматив хокукый актлары белән билгеләнмәгән булса, органга яисә оешмага документ һәм мәгълүмат бирә торган биш эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: документлар (белешмәләр) яисә Башкарма комитетка җибәрелгән баш тарту турында хәбәрнамә.

3.4. Кирәкле документлар булмау фактларын билгеләгәндә, бирелгән документларның регламент таләпләренә туры килмәве, гаризадагы яки бирелгән документлардагы мәгълүматларның туры килмәве, яки гаризада опекуннан яки попечительдән документларны кабул иткәндә кирәкле белешмәләр булмау, документларны кабул итү өчен җаваплы хезмәткәр дәүләт хезмәте күрсәтү өчен ачыкланган каршылыклар исемлеген төзи һәм гариза бирүчегә тапшырылган документлар белән бергә тапшыра.

Процедураларның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә кире кайтарылган документлар.

Гамәлләрне башкаруның максималь вакыты 10 минут тәшкил итә.

3.4.1. Опекун яки попечитель ризасызлык белдергән очракта, җитмәгән яисә тиешенчә рәсмиләштерелгән документлар, яисә аларны бирү мөмкинлеге булмаган, шулай ук баш тарту өчен башка нигезләнүләр булган очракта, белгеч мөрәҗәгать итүче (опекун) адресына дәүләт хезмәте күрсәтү өчен киртәләр булу турында язма хәбәр әзерли, анда аларны бетерү буенча чаралар күрү тәкъдим ителә һәм Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына кул кую өчен язма хәбәр тапшыра.

Процедураларның нәтиҗәсе: хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат проекты.

Максималь үтәү срогы-1 эш көне.

3.4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен киртәләр булу турында имзаланган язма хәбәр опекунга яки попечительгә кулга бирелә яки почта аша җибәрелә.

Процедураларның нәтиҗәсе: юлланган язма хәбәр.

Максималь үтәлеш вакыты-тиешле карар кабул ителгәннән соң 3 эш көне

3.5. Опека һәм попечительлек бүлеге белгече дәүләт хезмәте күрсәтү өчен документлар пакетын формалаштыра.

Опека һәм попечительлек органы стационар формада социаль хезмәтләр күрсәтүче социаль хезмәт күрсәтүне оештыруда балигъ булган бала артыннан күзәтчелек итү өчен түбәндәге гамәлләрне башкара:

а) балигъ булган баланың шәхси эшендә саклана торган документлар исемлеген һәм Балык Бистәсе Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары яки опека һәм

попечительлек органы җитәкчесе һәм стационар формада социаль хезмәт күрсәтүче оешма җитәкчесе кул куйган балигъ булган баланың шәхси эшен тапшыру турындагы актны төзи;

б) балигъ булган баланың шәхси эшендә саклanучы документларны стационар формада социаль хезмәт күрсәтүче социаль хезмәт күрсәтү оешмасының вазыйфаи затына исемлек нигезендә тапшыра;

в) балигъ булган баланы стационар формада социаль хезмәт күрсәтүче оешмага җибәрү турында акт, шулай ук шәхси эшне тапшыру турында акт һәм документлар исемлеген саклый.

Социаль хезмәт күрсәтүнең стационар учреждениеләренә күзәтчелек итү өчен урнаштырылган балигъ булганнарның шәхси эшләрен алып бару һәм аларның шәхси эшләрендәге документлар исемлеген төзү социаль хезмәт күрсәтү оешмасының стационар формада социаль хезмәт күрсәтүче вәкаләтле белгече тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Балигъ булган баланың стационар формада яки сәламәтлек саклау учреждениесендә социаль хезмәт күрсәтүче оешмада булуы тәмамланганнан соң аның шәхси эше балигъ булган баланың яшәү урыны буенча муниципаль берәмлек Башкарма комитетының опека һәм попечительлек органына җибәрелә.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм формалары

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатын контрольдә тоту мөрәҗәгать итүчеләрнең хокукларын бозу очракларын ачыклау һәм юкка чыгару, дәүләт хезмәте күрсәтү процедураларының үтәлешен тикшерү, опека һәм попечительлек органы вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләре булган мөрәҗәгатьләргә карата карарлар кабул итү һәм җаваплар әзерләү, шулай ук опека һәм попечительлек органы вазыйфаи затларының хәл ителешенә керә.

Административ процедураларның үтәлешен контрольдә тоту формалары булып торалар:

- дәүләт хезмәте күрсәтү буенча документлар проектларына хокукый экспертиза үткәрү. Экспертизаларның нәтиҗәсе булып проектларны визалау тора;
- билгеләнгән тәртиптә эш башкару алып баруын тикшерү үткәрелә;
- билгеләнгән тәртиптә дәүләт хезмәте күрсәтү процедураларының үтәлешен контрольдә тоту тикшерүләре үткәрү.

Билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча, мөрәҗәгать итүчеләрнең хокукларын бозу очраклары ачыкланган, шулай ук конфиденциаль белешмәләр таратылган очракта мәгълүмат гаепле затларны Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тарту өчен Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә җибәрелә. Контроль тикшерүләр планлы рәвештә һәм планнан тыш булырга мөмкин.

Планлы тикшерүләр 3 елга 1 тапкырдан да артыграк үткәрелергә тиеш түгел.

4.2. Административ процедуралар билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеген саклауга, белгечләр тарафыннан карарлар кабул итүгә, дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булуына, шулай ук конфиденциаль мәгълүматларның читкә чыгарылуына контроль Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек бүлеге җитәкчесе һәм муниципаль берәмлек Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.3. Муниципаль берәмлек Башкарма комитетының опека һәм попечительлек бүлеге белгечләренең җаваплылыгы аларның вазыйфаи регламентларында закон таләпләре нигезендә билгеләнә.

4.4. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе әлеге Регламентның 3 бүлегендә күрсәтелгән административ гамәлләрне вакытында һәм (яисә) тиешенчә үтәмәгән өчен җаваплы.

4.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү барышында гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтүне тикшереп тору дәүләт хезмәте күрсәткәндә эшчәнлекнең ачыклыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм мөрәҗәгатьне (шикаятьләрне) судка кадәр карау мөмкинлеге турында тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат алу юлы белән гамәлгә ашырыла.

**5. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче органнарның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, КФҮ, КФҮ хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе.**

5.1. Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның, дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның вазыйфаи затының яисә судтан тыш (судтан тыш) тәртиптә Башкарма комитетның хезмәткәрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьне Башкарма Комитет җитәкчесенә, Башкарма Комитет җитәкчесе карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьне муниципаль берәмлек Советына.бирергә хокуклы.

КФҮ хезмәткәре, КФҮнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына), шикаять законнарда билгеләнгән тәртиптә белдерелә.

Мөрәҗәгать итүче шикаять белән мөрәҗәгать итә ала, шул исәптән түбәндәге очракларда:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза бирүченең гаризасын теркәү срогын бозу;

2) дәүләт хезмәтләрен күрсәтү срогын бозу.

3) мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районының норматив хокукый актларында каралмаган документлар яисә мәгълүмат тапшыруны таләп итү;

4) мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, муниципаль хокукый актлары белән билгеләнгән документларны кабул итүдән баш тарту;

5) әгәр баш тарту нигезләре федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган булса,дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту;

6) Дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, муниципаль берәмлек норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп итү;

7) Башкарма комитетның, Башкарма комитетның хезмәткәре, күп функцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, дәүләт хезмәтләрен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән опечаткаларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуы яисә мондый төзәтмәләрнең билгеләнгән срогын бозу;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү вакытын яки тәртибен бозу;

9) федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда туктатып тору нигезләре каралмаган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору;

10) мөрәҗәгать итүченең, дәүләт хезмәте күрсәткәндә, булмаган һәм (яисә) төгәл булмаган дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән башта ук баш тартканда яисә, Федераль законның 16 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында каралган очраклардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда күрсәтелмәгән документлар яисә мәгълүмат  таләп ителгән очракта. Күрсәтелгән очракта мөрәҗәгать итүче тарафыннан судка кадәр (судтан тыш) күпфункцияле үзәк карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять бирү, әгәр шикаять бирелә торган күпфункцияле үзәккә һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата Федераль законның 16 статьясындагы 1.3 өлешендә билгеләнгән тәртиптә тиешле дәүләт хезмәтләре күрсәтү функциясе йөкләнгән булса, мөмкин.

5.2. Шикаять язма рәвештә кәгазьдә, электрон формада муниципаль хезмәт күрсәтүче Башкарма комитетка, КФҮкә бирелә. Муниципаль хезмәт күрсәтүче Башкарма комитет җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр муниципаль берәмлек Советына тапшырыла.

КФҮнең, КФҮ хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр законнарда билгеләнгән тәртиптә бирелә.

Муниципаль хезмәт күрсәтүче Башкарма комитетның, муниципаль хезмәт күрсәтүче Башкарма комитетның вазыйфаи затының, муниципаль хезмәт күрсәтүче Башкарма комитет җитәкчесенең, муниципаль хезмәт күрсәтүче Башкарма комитет җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять почта аша, КФҮ аша, "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрен, Балык Бистәсе муниципаль берәмлегенең рәсми сайтын кулланып, КФҮнең читтән торып эш урынын җибәрергә мөмкин (КФҮ). http://www. balyk-bistage@tatarstan.ru Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталы http://uslugi.tatarstan.ru Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) бердәм порталы http://www.gosuslugi.ru һәм шулай ук гариза бирүченең шәхси кабул итү вакытында да кабул ителергә мөмкин.

5.3. Шикаять үз эченә түбәндәге мәгълүматны алырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять бирелә торган дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки муниципаль хезмәткәрнең исеме;

2) фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), мөрәҗәгать итүченең – физик затның яшәү урыны яисә исеме турында мәгълүмат, мөрәҗәгать итүченең – юридик затның урнашу урыны турында мәгълүмат, шулай ук элемтә өчен телефон номеры (номерлары), мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә тиеш электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм почта адресы;

3) шикаять бирелә торган дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи заты яисә муниципаль хезмәткәр карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмаулары) турында мәгълүмат;

4) мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының, муниципаль хезмәткәрнең карары һәм гамәле (гамәл кылмавы) белән килешмәве нигезендә торган дәлилләр.

5.4. Шикаятьне карау срогы - аны теркәгән көннән соң унбиш эш көне эчендә башкарыла. Муниципаль хезмәт күрсәтүче орган (учреждение), муниципаль хезмәт

күрсәтүче орган (учреждение хезмәткәре) вазыйфаи заты (учреждение хезмәткәре) тарафыннан шикаять белдерелгән очракта, мөрәҗәгать итүчедән документлар кабул итү яисә җибәрелгән опечаткаларны һәм хаталарны төзәтүдә яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогы бозылуга шикаять белдерелгән очракта-теркәлгән көннән биш эш көне эчендә башкарыла.

5.5. Шикаятькә шикаятьтә бәян ителгән шартларны раслый торган документларның күчермәләре дә кушылырга мөмкин. Бу очракта шикаятьтә аңа кушып бирелә торган документлар исемлеге китерелә.

5.6. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять, шул исәптән кабул ителгән карарны юкка чыгару, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән төгәлсезлек һәм хаталарны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлары белән каралмаган акчаларны кире кайтару рәвешендә дә канәгатьләндерелә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла. Мөрәҗәгать итүчегә әлеге пунктта күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән соң килүче  да соңга калмыйча язма рәвештә һәм мөрәҗәгать итүче теләге буенча электрон формада шикаятьне карау нәтиҗәләре турында мотивацияле җавап җибәрелә.

5.7. Мөрәҗәгать итүчегә әлеге статьяның 8 өлешендә күрсәтелгән җавапта шикаятьне канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган, күпфункцияле үзәк яисә Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә каралган оешма тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән бетерү максатларында гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук бирелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәтен алу максатларында мөрәҗәгать итүчегә алга таба тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.8. Шикаять җавапта канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип танылган очракта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында дәлилләнгән аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

5.9. Шикаятьне карау барышында яки карау нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу яки җинаять составы билгеләре билгеләнгән очракта, шикаятьләрне карау буенча вәкаләтләр бирелгән хезмәткәр, вазыйфаи зат, булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

Опека һәм попечительлек бүлеге карамагында булганнарның милке белән алыш-биреш ясау өчен рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кушымта (форма)

Балык Бистәсе муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе
___________________________________

_________________________________
___________________________________
(Ф.И.О. тулысынча)
адресы буенча яшәүче:
___________________________________

___________________________________

(тулы адрес)
телефон:

паспорттагы

(серия, номер, кем тарафыннан һәм

бирелгән)

_

__

__,

____________________________

мәгълүмат________________

кайчан

ГАРИЗА

__________________________________________________________________________ адресы буенча урнашкан торак йортта урнашкан (хосусыйлаштырылган, кооператив, дәүләт) фатирны читләштерүгә (сату-алуга, алмаштыруга), рөхсәт бирүегезне сорыйм
гомуми мәйданы__кв.м., торак мәйданы___кв.м., бүлмә саны _____________________________.

Читләштерелүче милекнең милекчесе булып (ф.и.о., өлешләрнең күләме)____________________

Шул исәптән эшкә яраксыз, яки чикләнгән рәвештә эшкә сәләтсез милекче (ф.и.о., өлешләрнең күләме)

____________________________________________________________________________________________

(Торак шартларын яхшырту, күченеп китү һ.б.) сәбәпле __________________________ _____________________________________________________________________________(гомуми мәйданы)___________(торак мәйданы)____________(бүлмәләр саны)___________ булган һәм _________________________________________________________________ адресы буенча урнашкан ___________________________(җир кишәрлегендә урнашкан торак йорт, фатир) сатып алабыз, анда эшкә яраксыз, яки чикләнгән рәвештә эшкә сәләтсез затка ____________.күләмендә өлеш бүленеп биреләчәк.

Өстәмә мәгълүмат (кредит җәлеп итү, сатып алынган фатир залог итеп тапшыру һәм башка чикләүләр)

____________________________________________________________________________________________.

Эшкә сәләтсез кешенең милек һәм торак хокуклары чикләнми.

ТР буенча дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәте идарәсендә торак бинаны гражданнар милкенә тапшыру турындагы килешүне теркәгәннән соң ике атна эчендә опека һәм попечительлек бүлегенә торак бинаны гражданнар милкенә тапшыру турындагы килешүнең һәм хокукны дәүләт теркәвенә алу турындагы таныклыкларның күчермәләрен тапшырырга тиешмен.

Шәхси мәгълүматлар белән эшләүгә рөхсәт бирәм.

__________ ___________

(дата) (имза)

Опека һәм попечительлек бүлеге карамагында булганнарның милке белән алыш-биреш ясау өчен рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 2нче кушымта

Балык Бистәсе муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе
__________________________________

–

________________________________
__________________________________
(Ф.И.О. тулысынча)
адресы буенча яшәүче:
__________________________________

—

__________________________________

—,

(тулы адрес)
телефон:

___________________________

паспорттагы

мәгълүмат________________

(серия, номер, кем тарафыннан һәм

кайчан

бирелгән)

ГАРИЗА

Түбәнгеләрдән гыйбарәт булган күчемсез милекне сатуга рөхсәт бирүегезне сорыйм:
______________________________________________________________________________
___ Милекнең техник характеристикасы
_______________________________________________.
Агымдагы елга мөлкәтнең бәяләү бәясе ______________________________.
Милекче булып карамактагы ______________________( ф и о) тора.

Нигезе ____________________________________________________________
(закон буенча мирас хокукы турында таныклык һ.б.)
______________________________________________________________________________
_____
Сатылган милек урынына карамактагы зат счетына ___________________________
күләмендә акча кертелә.
Карамактагы зат хокуклары кимсетелми.
Балигъ булмаган баланың шәхси мәгълүматлары белән эшләргә ризалык бирәм.

Өстәмә мәгълүмат :______________________________________________________________

(дата) (имза)

Опека һәм попечительлек бүлеге
карамагында булганнарның
милке белән алыш-биреш ясау
өчен рөхсәт бирү буенча дәүләт
хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
кушымта (белешмә)

**Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи затлар реквизитлары**

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек бүлеге**

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Бүлек җитәкчесе | (8-84361)22-2-04 | Guzaliya.Bagautdinov@tatar.ru |
| Бүлек белгече | (8-84361)22-2-04 | Razina.Shakirova@tatar.ru |

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты**

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Башкарма комитет җитәкчесе | (8-84361 )22-500 | balyk-bistage@tatar.ru |
| Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары | (8-84361 )22-705 | balyk-bistage@tatar.ru |